**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**НИЖНЕКАРМАЛКИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

423102, СЕЛО НИЖНЯЯ КАРМАЛКА, УЛ.ЛЕНИНА, Д.44

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**ТҮБӘН КАРМАЛКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423102, ТҮБӘН КАРМАЛКА АВЫЛЫ, ЛЕНИН УРАМЫ, 44 ЙОРТ

Тел.: (84396)2-39-47 ФАКС: (84396) 2-39-47
Email: Nkar.Cmn2@tatar.ru

05.12.2024 ел № 8

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кармалка авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кармалка авыл җирлеге башкарма комитеты баш бухгалтеры хезмәтенә түләүне оештыру һәм шартлары турында» 2019 елның 15 апрелендәге 4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 2024 елның 7 октябрендәге 03-12/7086 номерлы хатын үтәү йөзеннән, авыл җирлеге башкарма комитеты баш бухгалтерының социаль гарантияләрен тәэмин итү һәм хезмәт өчен түләүне тәртипкә китерү максатларында, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кармалка авыл җирлеге башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кармалка авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кармалка авыл җирлеге башкарма комитеты баш бухгалтеры хезмәтенә түләүне оештыру һәм шартлары турында» 2019 елның 15 апрелендәге 4 номерлы карарына (21.11.2022 ел № 15, 20.06.2024 ел № 6 үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. «Түбән Кармалка авыл җирлеге башкарма комитеты баш бухгалтерының хезмәт хакын оештыру һәм аның шартлары турындагы нигезләмә»нең 3 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: «Баш бухгалтерның хезмәт хакы 25700,00 сум (егерме биш мең җиде йөз сум) күләмендә билгеләнә».

2. Хезмәткәрләрнең вазыйфаи бурычлары күләме һәм шул ук квалификациядәге эшләр башкарылуы сакланып калганда, хезмәткәрләрнең хезмәт хакының әлеге карар нигезендә билгеләнә торган күләме 2024 елның 31

декабренә түләнә торган хезмәт хакы күләменнән ким була алмый.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районының
Түбән Кармалка авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе А.Ф. Митякин